| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА<br>БОЛЬШЕАТРЯССКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ТЕТЮШСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ТӘТЕШ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗУР ӘТРӘЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

тел. (84373) 58-3-05, факс 58-3-05

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**02 .11. 2024** **№ 5**

**2025 елда гражданнарга үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Кече Әтрәч торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Зур Әтрәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 20 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кече Әтрәч авылы, Җиһаншин урамы, 61 йорт адресы буенча урнашкан Кече Әтрәч авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Кече Әтрәч торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Зур Әтрәч авыл җирлегенең Кече Әтрәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы Сез, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, аерым алганда: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотумы?»

» КАРШЫ «РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Зур Әтрәч авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Зур Әтрәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче урынбасары** **Р.И. Вафин**